ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАЧЕЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 200, с.Качелино ,
Арский муниципальный район, 422013

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘЧЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк урам, 200 йорт, Кәче авылы,
Арча муниципаль районы, 422013

Тел. (84366)52-3-93, факс (84366)52-3-93 E-mail: Kach.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

**«18 » декабрь 2020 ел** **№ 41**

**«Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчалары җыю Тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы составына керә торган торак пунктларда халык җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» Кәче авыл җирлеге советының 31.10.2019 ел, № 93 карары, 07.11.2020 ел, № 1, 10.11.2020 ел, №2 от 13.11.2020 г. № 3 җыеннарда кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатыннан, Кәче авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1.«Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчалары җыю Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм ТР, Арча районы, Кәче авылы, Үзәк урам, 200 нче йорт; ТР, Арча районы, Чулпан авылы, Гагарин урамы, 7а;ТР, Арский район, д. Якты-Көн, Якты урам, 30а йорт адреслары буенча гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Кәче авыл җирлеге Башкарма комитетының 30.12.2019ел, № 72 «Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында" карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кәче авыл
җирлеге башлыгы Шаһиәхмәтов Р.Д.

Кәче авыл җирлеге
башкарма комитетының
18.12.2020 ел, № 41 кара-
рына 1 нче кушымта

**«Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчалары җыю Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип «Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү, җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә күрсәткән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, 2021 елның 21 февраленә кадәр муниципаль берәмлек территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан башкарыла.

3. Аерым категория гражданнар өчен:

а) көндезге уку формасы буенча укучы студентлар,

б) 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен

түләү күләме җирле җыеннар карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

4. Нигезле сәбәпләр булганда:

а) гаилә әгъзасының үлеме (ата-ана, хатыны/ире, балалары),

б) янгын яки башка табигый бәла-казалар нәтиҗәсенә зыян килү,

гражданнарга гариза нигезендә өч айдан да артмаган вакытка түләү кертүне кичектереп тору каралган булырга мөмкин.

5. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәр (хәбәрнамә) бланкы гражданнар игътибарына (http://pravo.tatarstan.ru) сайтында басылып чыгу юлы белән хәбәр ителә һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында ( http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмати стендларда, шулай ук кул куйдырып үзенә тапшыру яисә почта аша җибәрү юлы белән халыкка җиткерелә.

Хәбәрдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерү өчен түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар «Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша почта күчермәләрен (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру юлы белән башкарыла, «Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең башкарма комитеты кассасы яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша сылтама https://uslugi.tatarstan.ru/ буенча башкарыла.

8. Түләүне дәлилли торган документ булып керем касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Кәче авыл җирлеге башкарма
комитетының 18.12.2020 ел,
№41 карарына 2 нче кушымта

ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № _______________
«Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләү турында

Түләүченең ф. и. а.и.________________________________________________________
Адресы:______________________________________________________________
____________________________________________________________нигезендә
Сезгә __________ кадәр ________ сум күләмендә
____________________________________чаралар гамәлгә ашыру өчен
түбәндәге реквизитлар буенча:
БИК банк ___________________________
Сч. № ________________________________________
Счетны алучы. № _______________________________
ИНН ____________________________________________
КПП ____________________________________________
КБК __________________ОКАТО_________________
Түләү билгеләнеше
___________________________________________________________________________бер
тапкыр түләү түләргә кирәк.

Җитәкче __________________ ________________________________________

М. у. (имза) ( имзаны аңлату)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

«__________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына __ сум күләмендә бер мәртәбә түләнә торган үзара салым түләү буенча хәбәр (хәбәрнамә) № ___
Түләүченең ф. и. а.и.____________________________________________
Адресы: ________________________________________________
Алдым «___» _______________ 20__ ел ___________________________________
(имза/түләүченең ф.и.а.и.)

*Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән бирелгән очракта, өзмә корешок тутырыла һәм ул Кәче авыл җирлеге башкарма комитетында кала.*